РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» декабрь 2022г. г. Альметьевск № 92

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт ечен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең тикшерү - хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында «2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә», Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдимнәре белән

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 67 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 82 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибендә һәм шартларында:

а) 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) түләү тәртибе муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен үтәүне, вазыйфаи инструкцияне үтәүне тәэмин итүне исәпкә алып, яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан билгеләнә торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен, шул исәптән хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән ечен айлык премия;»;

б) тәртипнең 2 пункты 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләкләү, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын муниципаль хезмәт вазыйфасына, элек билгән вазыйфаи оклады белән билгән муниципаль хезмәт вазыйфасына гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда билгеләнү очрагы керми;»;

карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре»

(сумнарда)

| «Вазыйфаның исеме» | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 34 766 |
| Идарә җитәкчесе, местәкыйль бүлек җитәкчесе (медире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 24 108 |
| Идарә җитәкчесе урынбасары, местәкыйль бүлек җитәкчесе урынбасары (медире), башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 20 174 |
| Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 20 174 |
| Башкарма комитетның идарә составындагы бүлек җитәкчесе | 20 174 |
| Сектор медире | 18 906 |
| Баш белгеч | 18 525 |
| Әйдәүче белгеч | 17 383 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 16 114» |

1.2 2 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен хезмәт хакына айлык естәмә түләү күләмнәре

| Өстәмә түләү исеме | Хезмәт окладына айлык естәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Серлелек дәрәҗәсе булган «бетенләй яшерен» мәгълүматлар белән эшләгән ечен | 30 - 50 |
| Рөхсәт рәсмиләштергәндә «яшерен» яшеренлек дәрәҗәсе булган белешмәләр белән эшләгән ечен<br>- тикшерү чараларын үткәреп<br>- тикшеру чараларын үткәрмичә | <br><br>10 - 15<br>5 - 10 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Ф.А. Шәйхетдинова).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов